# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **15.11.2024 ел.**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Чубар-Абдул авыл җирлегенэ керүче
Буралы авылында 2025 елда үзара салым
жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чуар-Абдул авыл җирлеге составына керүче Буралы авылы җирлегендә гражданнар җыены гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Сез, 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толл хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар, аларның гаилә әгъзаларыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:

- ремонт, коймаларны кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратны әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, кабул ителгәннән соң, 10 көннән соң, соңга калмыйча түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы, Буралы авылы, Октябрьская урамы, 34 йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгы: Н. Ә. Фәтхетдинов